| МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2024 № 437-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 26 декабрендәге 610-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 26 декабрендәге 610-осн номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 30 сентябрендәге 375-осн номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

4.1 подпунктта «хисаплылыктан өземтәләр» сүзләрен «белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтүнең бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итүдә күрелгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;»;

4.3 пунктчада:

алтынчы абзацны түбәндәгечә үзгәртеп бирергә:

«штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында акт яки бюджет керемнәре администраторы Татарстан

Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә:

аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлангач (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта).»;

1 нче кушымта атамасында «Хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «Белешмә» сүзенә алмаштырырга;

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А. Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров